**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«01» 08 2022 ел Яр Чаллы №65

Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегендә урнашкан 16:39:110205:103 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 35, 36, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районының Калмаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Тукай муниципаль районы уставы, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Тукай муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзелешен алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча ведомствоара комиссиясенең 2022 елның 1 июлендәге карары нигезендә, Тукай муниципаль районы һәм Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге халкының уңайлы тормыш шартларына хокукларын, Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ**

1. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегендә урнашкан 16:39:110205:103 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Шәхси хуҗалык алып бару» төп төрдән «Бакчачылык алып бару» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2.1. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы рәсми сайтында һәм Калмаш авыл җирлеге Башкарма комитетының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Халык тыңлауларын бер көндә, **2022 елның 15 сентябрендәге 15:00 сәгатьтә** үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай районы, Калмаш авыл җирлеге, Калмаш авылы, Үзәк ур., 32, “Яшьлек” мәдәният йорты бинасы.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше секторы мөдире О. А. Никитинага билгеләргә.

5. Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Ф. М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 08.07 65 номерлы карарына кушымта

Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге тәртип җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарының фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Тукай муниципаль районы халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр **2022 елның 11 августыннан 2022 елның 14 сентябренә кадәр** түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.

3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Халык тыңлаулары секретаре фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

5. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

6. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

7. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

8. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

9. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм Тукай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.